**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 7 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың алты биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 150 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **43**. Уңышлар!

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- тарихи вакыйга һәм шәхесләр турында буыннан-буынга тапшырылып килгән хикәят;
- тарихи вакыйгаларның шаһиты булган кешеләр авызыннан сөйләнә;
- ике төркемгә – тарихи һәм топонимик төрләргә бүлеп йөртәләр.

**Җавап**: риваять

**2. Һәр төркемдә артык булган төшенчәне билгеләгез (3 балл):**

а) сатира, юмор, афоризм, сарказм

ә) йола һәм уен-бию җырлары, мөнәҗәтләр, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар

б) хикәя, баллада, новелла, повесть


**Җавап:**

а) афоризм

ә) мөнәҗәтләр

б) баллада

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Һади Такташ

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

б) Мамадыш өязе Тулбай авылы

в) Уфа губернасы Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылы

**Җавап:** а) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Мокамай», «Матурлык», «Исемдә калганнар», «Алсу».

ә) «Мокамай», «Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Җир уллары трагедиясе».

б) «Мокамай», «Онытылмас еллар», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Фронтовиклар».

в) «Мокамай», «Җир уллары трагедиясе», «Алсу», «Матурлык».

**Җавап:** ә) «Мокамай», «Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Җир уллары трагедиясе».

**4. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын билгеләгез. (6 балл)**

а) Басма, тарак, малай, этләр.

**Җавап:** Г. Тукай “Су анасы”

ә) Без, Бәдретдин, Хозыр Ильяс, скрипкә, ана, чәчәк авыруы.

**Җавап**: Ә. Еники “Матурлык”

б) Әкияттәге ике бала, ике ыштансыз малай, ак каен, канлы пычак, чабата

**Җавап:** Һ. Такташ “Мокамай”

**5. Шигырьне укыгыз, төшеп калган сүзләрне өстәп языгыз (3 балл). Сорауларга җавап бирегез.**

Барыгыз болынга, балалар!
Йөгерегез, уйнагыз, __________! (көлегез)
Елмайсын күреп шат аналар,
Юансын боеккан күңлегез.

Болында күп матур чәчәкләр,
Барсы да татлы хуш ислеләр.
Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр,
Нәкъ сезнең иренегез төслеләр.

Җил көйләп тирбәтә аларны,
Иркәли кояшның нурлары.
Алар бит изге Җир-ананың
Сөекле кызлары, ___________.(уллары)

Бу җирдә күп булды сугышлар,
Янгыннар, явымнар, давыллар,
Киселде күп батыр тормышлар,
Янды зур калалар, авыллар.

Ил өчен барды бу зур көрәш,
Давыллы, дарылы елларда.
Сеңде бу туфракка күпме ________, (яшь)
Күпме кан тамды бу кырларга.

Шул каннар һәм яшьләр аркылы,
Ил бөек җиңүгә иреште.
Яз килде; дулкынлы, ялкынлы,
Чәчәккә төренде җир өсте.

Бу гөлләр шытты Җир-ананың
Яралы йөрәге түрендә.
Ничек ул йөрәкнең янганын
Мин күрәм аның һәр гөлендә.

Җыегыз, балалар, сез җирнең
Бу нәфис һәм иркә гөлләрен.
Китерегез данлыклы хөр илнең,
Тәбрикләп, шатлыклы көннәрен.

Сез безгә шулкадәр кадерле,
Шулкадәр ягымлы, сөйкемле!
Ал таңы алдагы дәвернең
Йөзегездә чагыладыр шикелле.

Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,
Дәрт биреп безнең шат күңелгә.
Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр
Бит җиңеп алынган гомергә.

**а) Әсәрнең исеме (1 балл) Җавап:** “Чәчәкләр”

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл) Җавап:** Муса Җәлил

**б) Автор укучыга лирик геройның нинди хисләрен җиткерә? (2 балл)**

**Җавап:** шатлану, куану, юану, горурлану, соклану хисләре

**в) Шигырь текстыннан**

- **сынландыруга мисаллар табып языгыз (2 балл)**

  **Җавап:** Җил көйләп тирбәтә аларны; иркәли кояшның нурлары.

- **чагыштыруга мисаллар китерегез (2 балл)**

  **Җавап:** Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр, нәкъ сезнең иренегез төсләре; ал таңы алдагы дәвернең йөзегездә чагыладыр шикелле.

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (2 балл)**

Җавап: боеккан күңел, татлы хуш исле чәчәк, батыр тормышлар; сөекле кызлар, уллар; бөек җиңү; яралы йөрәк, давыллы, дарылы еллар; дулкынлы, ялкынлы яз һ.б.

**6. Үзегез яраткан әдәби геройны исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан геройның исемен, кайсы әсәрдән алынганлыгын, авторын күрсәтегез. Күләме 8-10 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 8 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың алты биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 150 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **43**. Уңышлар!

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- бу жанрга ике юллылык хас;
- нигезендә кайгылы яки көлкеле вакыйга ята;
- тарихи вакыйгаларның шаһиты булган кешеләр авызыннан сөйләнә.

**Җавап:** бәет

**2. Һәр төркемдә артык булган төшенчәне билгеләгез (3 балл):**

а) хикәя, новелла, баллада, повесть

ә) сатира, афоризм, юмор, сарказм

б) бәет, лирик җыр, дастан, мөнәҗәт


**Җавап:**

а) баллада

ә) афоризм

б) лирик җыр

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Мәҗит Гафури

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) Уфа губернасы Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылы

ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

б) Арча районы Кушлавыч авылы

в) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

**Җавап:** ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Милли моңнар», «Ана», «Имән».

ә) «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Бездә – яздыр», «Ана», «Кәҗүл читек», «Җир уллары трагедиясе».

б) «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Ана», «Ана теле», «Кара йөзләр».

в) «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Җир уллары трагедиясе», «Видагъ», «Матурлык».

**Җавап:** б) «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Ана», «Ана теле», «Кара йөзләр».

**4. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын билгеләгез. (6 балл)**

а) Теплушка, җимерек станция, яралы, җыр, Таһирә, ялгыз кабер.

**Җавап:** Ә. Еники “Кем җырлады?”

ә) Печән өсте, чалгы, Агыйдел, өмә, Әсма, мәхәббәт.

**Җавап:** Г. Ибраһимов “Табигать балалары”

б) Әкияттәге ике бала, ике ыштансыз малай, ак каен, канлы пычак, чабата.

**Җавап:** Һ. Такташ “Мокамай”

**5. Шигырьне укыгыз, төшеп калган сүзләрне өстәп языгыз (3 балл). Сорауларга җавап бирегез.**

...Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары,
Ак кар булып җиргә ___________. (коела)

Туңган тәрәзәне эретеп, мин
Мыштым гына карыйм _________, (урамга)
Ак чәчәкләр ява урамда.

Берәү, борын очын кулына тотып,
Сүгенә-сүгенә кайта салкыннан,
Җил ияреп килә артыннан...

Туңган тәрәзәне эретеп, ул
Мыштым гына карый ___________, (урамга)
Ак чәчәкләр ява урамда.

Берәү, борын очын кулына кысып,
Сүгенеп узды кышкы салкыннан,
Ә җил, мыштым гына, эндәшмичә,

Ияреп килә минем артымнан...

Шуның өчен дә мин, чыкмый гына,
Тәрәзәдән карыйм ___________, – (урамга)
Ак чәчәкләр ява урамда...

Ак чәчәкләр ява, дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары,
Ак кар булып җиргә ___________... (коела)

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** Ак чәчәкләр

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Һади Такташ

**б) Автор укучыга лирик геройның нинди хисләрен җиткерә? (2 балл)**

**Җавап:** матурлыкка соклану.

**в) Шигырь текстыннан**

- **сынландыруга мисал табып языгыз (2 балл)**

  **Җавап:** җил, мыштым гына, эндәшмичә, ияреп килә минем артымнан

- **чагыштыруга мисал китерегез (2 балл)**

  **Җавап:** гүя йолдызлары, ак кар булып җиргә коела

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (2 балл)**

**Җавап:** ак чәчәкләр, матур дөнья.

**6. Үзегез яраткан әдәби геройны исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан геройның исемен, кайсы әсәрдән алынганлыгын, авторын күрсәтегез. Күләме 8-10 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 9 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **51**. Уңышлар!

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- ул халык авыз иҗатының иң кыска жанры;
- ул күчерелмә мәгънәле афористик гыйбарә, хикмәтле сүз дигәнне аңлата;
- сүзне сәнгатьчә бизәү, эмоциональ көчен арттыру вазифасын үти.

**Җавап:** әйтем

**2. Һәр төркемдә артык булган төшенчәне билгеләгез (3 балл):**

а) хикәя, новелла, роман, баллада

ә) драма, комедия, нәсер, трагикомедия

б) такмак, мәдхия, дастан, мөнәҗәт

**Җавап:**

а) баллада

ә) нәсер

б) мәдхия

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (2 балл)**

**Җавап:** Гамил Афзал

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Татарстанның хәзерге Зәй районы Биш Субашы авылы

ә) Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылы

б) Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылы

в) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

**Җавап:** ә) Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Юл газабы», «Өф-өф итеп», «Киләчәккә кайту», «Йөз кабат».

ә) «Юл газабы», «Туган авыл», «Мокамай», «Айлы кичләр», «Мыек борам».

б) «Юл газабы», «Йөз кабат», «Айлы кичләр», «Мыек борам».

в) «Юл газабы», «Алсу», «Мыек борам», «Мокамай».

**Җавап:** б) «Юл газабы», «Йөз кабат», «Айлы кичләр», «Мыек борам».

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

| | |
|---|---|
| 1) Исмәгыйль | а) «Хәят» |
| 2) Лиза | ә) «Галиябану» |
| 3) Закир | б) «Буранда» |
| 4) Мостафа | в) «Алмачуар» |

**Җавап:** 1) ә; 2) а); 3) в; 4) б.

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Кечкенә бала, азан, чана, җил, буран, солдат.

**Җавап:** Ш. Камал “Буранда”, хикәя

ә) Әкияттәге ике бала, ике ыштансыз малай, ак каен, канлы пычак, чабата.

**Җавап:** Һ. Такташ “Мокамай”, шигырь / поэма

б) Печән өсте, чалгы, Агыйдел, өмә, Әсма, мәхәббәт.

**Җавап:** Г. Ибраһимов “Табигать балалары”, хикәя

**6. Шигырьне укыгыз, төшеп калган сүзләрне өстәп языгыз (3 балл). Сорауларга җавап бирегез.**

Авыруыма табиб кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын,
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста __________. (һавасын)

Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе ___________! (тәмлерәк)

Яннарына барам агайларның,
Фикерләрен ишетеп карарга.
Җырларымда телим гомерем буе
Алар рухы белән ___________ . (янарга)

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** “Җырларымда телим”

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Сибгат Хәким

**б) Автор укучыга лирик геройның нинди хисләрен җиткерә? (3 балл)**

**Җавап:** соклану, горурлану, куану, сагыну

**в) Шигырь текстыннан**

- **метафорага мисаллар китерегез (2 балл)**

  **Җавап:** авыруга табиб кирәк түгел, йөрәк дәвасы, җырларымда (шигырьләремдә) телим, рух белән яну.

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (2 балл)**

  **Җавап:** чиста һава, шигъри хис, тәмле арыш исе, ямьле урын

**7. Үзегез яраткан әдәби геройны исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан исемен, кайсы әсәрдән алынганлыгын, әсәрнең авторын күрсәтегез. Күләме 10-12 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 10 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **50**. Уңышлар!

**1. Әдәбиятның кайсы жанры турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- ул гарәпчәдән белем, фәлсәфә, мәкаль дигәнне аңлата;
- кечкенә күләмле, үткен, кинаяле сүзгә корылган дидактик жанр;
- афористик формада акыллы, гыйбрәтле сүз әйтү, мәгънәле хәлне гәүдәләндерү тәшкил итә.

**Җавап**: хикмәт

**2. Һәр төркемдә артык булган төшенчәне билгеләгез (3 балл):**

а) такмак, мәрсия, дастан, мөнәҗәт

ә) хикәя, новелла, очерк, нәсер

б) драма, комедия, баллада, трагикомедия


**Җавап:**

а) мәрсия

ә) нәсер

б) баллада

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Мөдәррис Әгъләмов

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Татарстанның хәзерге Зәй районы Биш Субашы авылы

ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

б) Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылы

в) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

**Җавап:** а) Татарстанның хәзерге Зәй районы Биш Субашы авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Каеннар илендә», «Мокамай», «Киләчәккә кайту», «Юл газабы».

ә) «Каеннар илендә», «Туган авыл», «Мокамай», «Ана», «Киләчәккә кайту».

б) «Каеннар илендә», «Алсу», «Киләчәккә кайту», «Мокамай».

в) «Каеннар илендә», «Тукайдан хатлар», «Киләчәккә кайту», «Акмулла арбасы».

**Җавап:** в) «Каеннар илендә», «Тукайдан хатлар», «Киләчәккә кайту», «Акмулла арбасы».

**4. Мәүла Колый кайсы чор әдәбияты вәкиле булуын билгеләгез. (3 балл)**

а) Борынгы чор татар әдәбияты.

ә) Алтын Урда чоры әдәбияты.

б) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

в) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның II яртысы – XVIII гасыр).

**Җавап:** в) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның II яртысы – XVIII гасыр).

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Печән өсте, чалгы, Агыйдел, өмә, Әсма, мәхәббәт.

**Җавап:** Г. Ибраһимов “Табигать балалары”, хикәя

ә) Әкияттәге ике бала, ике ыштансыз малай, ак каен, канлы пычак, чабата.

**Җавап:** Һ. Такташ “Мокамай”, шигырь / поэма

б) Ана, дала, кылганнар, камчы, камчат бүрек, хәситә.

**Җавап:** Ә. Еники “Әйтелмәгән васыять”, хикәя / повесть

**6. Шигырьне укыгыз, төшеп калган сүзләрне өстәп языгыз (2 балл). Сорауларга җавап бирегез.**

Янып торган сүзләр эзләдем мин,
Ашкынулы хисләр кичердем;
Аяз көндә язган сүзләремнең
Ак аһәңен эчеп **_________**. (исердем)

Кайда килеп туктар юл азагы,
Ел үтәсе юлны ай үтәм.
Бөтен гомерем минем – **________**, (юл газабы)
Аннан татлы газап бар микән?

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** Юл газабы

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Гамил Афзал

**б) Автор укучыга лирик геройның нинди хисләрен җиткерә? (3 балл)**

**Җавап:** юану, куану

**в) Шигырь текстыннан**

- **метафорага мисаллар табып языгыз (2 балл)**

**Җавап:** аяз көн, ак аһәң, юл азагы, юл газабы

- **чагыштыруга мисал китерегез (2 балл)**

  **Җавап:** бөтен гомерем минем – юл газабы

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (2 балл)**

  **Җавап:** янып торган сүзләр,  ашкынулы хис, татлы газап

**7. Үзегез яраткан әдәби геройны исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әлеге геройның исемен, кайсы әсәрдән алынганлыгын, авторын күрсәтегез. Күләме 12–15 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы**
**11 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **51**. Уңышлар!

**1. Нинди формада иҗат ителгән әсәрләр турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- сюжет, катнашучылар бердәйлеге ярдәмендә бәйләнгән ике кисәктән торган роман яки драма әсәре;
- һәр кисәк сюжет, композиция, персонажларны төркемләү ягыннан үзенчә төгәлләнгән була;
- мондый форма, гадәттә тарихи әсәрләр язганда, тормышны үз агышы, хронология тәртибендә тасвирлаганда кулланыла.

**Җавап:** дилогия

**2. Һәр төркемдә артык булган төшенчәне билгеләгез (3 балл):**

а) такмак, хикмәт, дастан, мөнәҗәт

ә) хикәя, новелла, очерк, нәсер

б) романтизм, реализм, афоризм, футуризм

**Җавап:**

а) хикмәт

ә) нәсер

б) афоризм

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Дәрдмәнд

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Оренбург губернасы Оренбург өязе Акман авылы

ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

б) Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылы

в) Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылы

**Җавап:** б) Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Кораб», «Мокамай», «Ваксынмыйм», «Каләмгә хитаб».

ә) «Кораб», «Авыл», «Мокамай», «Шагыйрьгә».

б) «Кораб», «Бүзләрем маналмадым», «Каләмгә хитаб», «Шагыйрьгә».

в) «Кораб», «Уку», «Кыйтга», «Бүзләрем маналмадым».

**Җавап:** б) «Кораб», «Бүзләрем маналмадым», «Каләмгә хитаб», «Шагыйрьгә».

**4. Габдерәхим Утыз Имәни кайсы чор әдәбияты вәкиле булуын билгеләгез. (3 балл)**

а) Алтын Урда чоры әдәбияты.

ә) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

б) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның II яртысы – XVIII гасыр).

в) Яңарыш дәвере әдәбияты.

**Җавап**: б) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның II яртысы – XVIII гасыр).

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Печән өсте, чалгы, Агыйдел, өмә, Әсма, мәхәббәт.

**Җавап:** Г.Ибраһимов “Табигать балалары”, хикәя

ә) Ана, дала, кылганнар, камчы, камчат бүрек, хәситә.

**Җавап:** Ә.Еники “Әйтелмәгән васыять”, хикәя / повесть

б) Мәхәббәт, бала, ана, хат, җил, ай.

**Җавап:** Һ.Такташ “Мәхәббәт тәүбәсе”, поэма

**6. Шигырьне укыгыз, төшеп калган сүзләрне өстәп языгыз (3 балл). Сорауларга җавап бирегез.**

Әй, _________, син мең шәһәрдән (авыл)
Мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда....
Нинди тын һәм нинди буш!

Ул кара бер күгеңә бу
Фирүзә бит бик зуры,
Күр аеңны, кайда бар бу,
Бер гаҗәеп, бит нуры!

Нинди тамчы, тамчы нурлар
Сачрәгән күк __________,(йөзенә)
Чеп-чуар чын бриллиант
Сипкәнмени, күр, үзенә.

Һәм гаҗип бер яктылыкта

Җир көмеш төсле тора:
Анда урман һәм дә __________, (таулар)
Монда кырлар яктыра.

Синдә бар да чын матур һәм
Чын матур синдә генә,
Тагы да артыр бер матурлык
Китдисәм мин дә менә.

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** Авыл

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** С. Рәмиев

**б) Автор укучыга лирик геройның нинди хисләрен җиткерә? (3 балл)**

**Җавап:** соклану, горурлану, юану, куану.

**в) Шигырь текстыннан**

- **метафорага мисаллар табып языгыз (2 балл)**
  **Җавап:** бит нуры (ай); тамчы нурлар
- **чагыштыруга мисаллар китерегез (2 балл)**

  **Җавап:** күк йөзенә чеп-чуар чын бриллиант сипкәнмени; һәм гаҗип бер яктылыкта җир көмеш төсле тора

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (2 балл)**

**Җавап:** ямьле, хуш авыл; тын, буш урам; гаҗип яктылык; чын матурлык

**7. Үзегез яраткан әдәби геройны исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әлеге геройның исемен, кайсы әсәрдән алынганлыгын, авторын күрсәтегез. Күләме 12–15 җөмлә. (15 балл)**